| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кулегашского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Күләгәш авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.08.2018 Күләгәш авылы № 38-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советының карары 13 август 2013 ел №13-1 белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Күләгәш авыл җирлеге" муниципаль берлегенең җирдән куллану һәм төзелешләр Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон 06 октябрь 2003 ел № 131-ФЗ, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, "Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законына 29 декабрь 2017 ел, № 455-ФЗ туры китереп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советы к а р а р б и р д е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Карары 13 август 2013 №13-1 белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Күләгәш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән куллану һәм төзелешләр Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) Кагыйдәләрнең 17 маддәсе 13 пунктын яңа редакциядә язарга:**

"13. Җәмәгать фикер алышулары йә җәмәгать тыңлаулары йомгаклары турындагы заключение муниципаль хокук актларын, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастыру өчен билгеләнгән тәртиптә бастырыла һәм рәсми сайтта һәм (йә) мәгүлүмат системаларына урнаштырыла".

**2) Кагыйдәләрнең 18 маддә 2, 3 пунктларын яңа редакциядә язарга:**

"2. Җәмәгать фикер алышулары йә җәмәгать тыңлауларын үткәргәндә җәмәгать фикер алышуларында йә җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның җәмәгать фикер алышуларында йә җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итү максатында торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин.

3. Җәмәгать тыңлаулары түбәндәге этаплардан тора:

1) җәмәгать тыңлаулары башлану турында хәбәр итү;

2) җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектны һәм мәгълүмат материалларын рәсми сайтта урнаштыру һәм экспозицияне йә шундый проект экспозициясен ачу;

3) җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле экспозицияне йә проект экспозициясен үткәрү;

4) җыелыш йә җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җыелышларын үткәрү;

5) җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен әзерләү һәм оформить итү;

6) җәмәгать тыңлаулары йомгаклары турында заключение әзерләү һәм бастыру".

**3) Кагыйдәләрнең 19 маддә 1,2 пунктларын яңа редакциядә язарга:**

"1. Тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына, җир участокларын һәм капиталь төзелеш объектларын биләүчеләрнең территорияне планлаштыру һәм территорияне мижалау проектлары, расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертү каралган проектлар буенча кеше хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатында, Җирлек Уставы һәм (йә) Җирлек Советының норматив хокук актына туры китереп, Шәһәр төзелеше Кодексы положениеләрен исәпкә алып, җәмәгать фикер алышулары йә җәмәгать тыңлаулары үткәрелә, Шәһәр төзелеше Кодексында һәм башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш.

2. Җәмәгать фикер алышулары йә җәмәгать тыңлаулары үткәрү вакыты муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә бу турыда хәбәр иткәннән алып җәмәгать фикер алышулары йә җәмәгать тыңлаулары йомгаклары турында заключение басылганга кадәр муниципаль берәмлек Уставы һәм (йә) муниципаль берәмлек органының норматив хокук актлары белән билгеләнелә һәм ул бер айдан ким һәм өч айдан артык булмаска тиеш".

**4) Кагыйдәләрнең 21 маддәсе 2,5,6 пункталрын яңа редакциядә язарга:**

"2. Тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына, җир участокларын һәм капиталь төзелеш объектларын биләүчеләрнең җир участокларына йә капиталь төзелеш объектларыннан шартлы рәвештә куллану төренә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча, рөхсәт ителгән төзелештә чик параметрларыннан читләшүгә рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү буенча кеше хокукларын саклау максатында, Җирлек Уставына һәм норматив хокук актларына туры китереп һәм Шәһәр төзелеше Кодексы положениеләрен исәпкә алып җәмәгать фикер алышулары йә җәмәгать тыңлаулары үткәрелә".

5. Җәмәгать фикер алышулары йә җәмәгать тыңлауларын үткәрү вакыты муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә бу турыда хәбәр иткәннән алып, җәмәгать фикер алышулары йә җәмәгать тыңлаулары йомгаклары турында заключение басылганга кадәр муниципаль берәмлек органының норматив хокук актлары белән билгеләнелә һәм ул бер айдан да артык булмаска тиеш.

6. Кулланунының шартлы куллану төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын йә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны физик йә юридик зат күтәрә”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына http//agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштырырга.

3. Әлеге Карарны үтәүгә контрольне үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе Ю.Н.ВАСИЛЬЕВ